# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## Дәүләт хезмәте турында

Әлеге Закон, дәүләт органнарына караган эшләрнең Татарстан Республикасы Конституциясендә беркетелгәннәреннән чыгып, дәүләт хезмәте өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне һәм Татарстан Республикасындагы дәүләт хезмәткәрләренең хокукый хәлен җайга сала.

### 1 бүлек

### Гомуми нигезләмәләр

<u>1 статья.</u> Дәүләт хезмәте

Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары һәм Татарстан Республикасында гамәлдә булган башка закон актлары нигезендә дәүләтнең максатларын һәм вагыйфаларын үтәү өчен вазыйфаи вәкаләтләрне гамәлгә ашырудан гыйбарәт.

Дәүләт хезмәте вәкиллекле, башкарма һәм хөкем хакимиятләре органнарының аппаратларында, шулай ук дәүләт исеменнән аның вазыйфаларын башкаручы һәм Татарстан Республикасы закон актлары нигезендә дәүләтнең дәүләт хезмәте дип саналучы башка органнарында башкарыла. Судьялар һәм дәүләт органнарында, оешмаларында һәм учреждениеләрендә хезмәт шартнамәләре (контрактлары) яисә гражданлык-хокукый шартнамәләр нигезендә вакытлыча эшләүче гражданнар, шулай ук ярдәмче техник персонал дәүләт хезмәтендә эшли алмыйлар.

2 статья. Дәүләт хезмәте принциплары

Дәүләт хезмәте хокукый дәүләтнең түбәндәге принципларына нигезләнә:

законлылыкка;

закон чыгару, башкарма һәм хөкем хакимиятләренең бүленешенә;

сәләтләре һәм кәсби әзерлеге нигезендә, гражданнарның теләсә нинди дәүләт эше белән бернинди дискриминациясез шөгыльләнүгә тигез хокуклылыгына;

югарыдагы дәүләт органнарының һәм урындагы затларның үз вәкаләтләре чикләрендә кабул ителгән карарларының түбәндәге дәүләт органнары һәм урындагы затлар өчен мәҗбүрилегенә;

дәүләт органнарының һәм дәүләт хезмәткәрләренең тикшерелеп торучанлыгына;

дәүләт хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының икътисадый, җәмгыяви һәм хокукый якланышына;

хәбәрдарлыкка;

дәүләт хезмәткәрләренең үз вазыйфаларын тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплылыгына.

Дәүләт органнарында сәяси фиркалар һәм хәрәкәтләр төзелмәләренең эшчәнлеге рөхсәт ителми. Дәүләт хезмәткәрләре хезмәт вазыйфаларын үтәгәндә дәүләт мәнфәгатьләренә, гражданнарның хокукларын яклауга һәм закон актларына таяналар, алар сәяси фиркаләрнең һәм хәрәкәтләрнең карарларына бәйле булмыйлар.

3 статья. Дәүләт хезмәте турында законнар

Дәүләт хезмәте турында законнар Татарстан Республикасы Конституциясеннән, әлеге Законнан һәм Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган башка закон актларыннан гыйбарәт.

Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтенең кайбер төрләрен хокукый җайга салу Татарстан Республикасының тиешле закон актларына нигезләнеп башкарыла.

П б ү л е к

Дәүләт эш урыны

4 статья. Дәүләт эш урыны

Дәүләт эш урыны дәүләт органының вәкаләтләрен башкару вазыйфаларының бер өлешеннән гыйбарәт.

Татарстан Республикасында, вәкаләтләрнең асылына карап, конституциячел һәм хакими дәүләт эш урыннары билгеләнә.

Дәүләтнең иң югары конституциячел эш урынын биләүче затның хокукый статусы Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары һәм Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган башка закон актлары тарафыннан билгеләнә.

Хакими дәүләт хезмәте белән шөгыльләнүче затның хокукый статусы дәүләт органының вәкаләтләрен ачыклаучы закон актлары һәм башка хокукый актлар, шулай ук эш урыны турындагы тиешле күрсәтмә тарафыннан билгеләнә.

351



5 статья. Дәүләт эше урыннарының төрләре

Татарстан Республикасында дәүләтнең конституциячел дәүләт эш урыннарына түбәндәгеләр керә:

1) дәүләтнең иң югары конституциячел эш урыннары - Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Югары Советы Рәисе, Татарстан Республикасы Вице-президенты, Татарстан Республикасы Премьер-министры;

2) дәүләтнең баш конституциячел эш урыннары - Татарстан Республикасы Югары Советы Рәисенең урынбасарлары, Сәркатибе һәм Татарстан Республикасы Югары Советы даими комиссияләренең рәисләре, Татарстан Республикасы Прокуроры, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты әгъзалары, Татарстан Республикасы Милли банкы рәисе, Татарстан Республикасы Тикшерү комитеты рәисе, халык депутатлары җирле Советларының рәисләре, җирле хакимиятләрнең башлыклары.

Татарстан Республикасында дәүләтнең хакими эш урыннарына түбәндәгеләр керә:

1) дәүләтнең иң югары хакими эш урыннары - Татарстан Республикасы Президенты Аппараты җитәкчесе, Татарстан Республикасы Югары Советы Секретариаты башлыгы; Татарстан Республикасы Президентының, Татарстан Республикасы Югары Советының эшләр буенча идарәчеләре; Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты Секретариаты башлыгы; Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты составына кермәүче республика дәүләт органнары җитәкчеләре;

2) дәүләтнең баш хакими эш урыннары - Татарстан Республикасы Президенты Аппараты җитәкчесенең урынбасарлары, Татарстан Республикасы Югары Советы Секретариаты башлыгы урынбасарлары;

Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы Премьер-министры киңәшчеләре; Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Югары Советы, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты, министрлыклар һәм ведомстволар, республиканың башка дәүләт органнары аппаратларының төзелмә бүлекчәләре җитәкчеләре һәм аларның урынбасарлары; Татарстан Республикасы Президентының һәм Татарстан Республикасы Югары Советының эшләр буенча идарәчеләренең урынбасарлары; Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты Секретариаты башлыгының урынбасарлары; Татарстан Республикасы Президентының, Татарстан Республикасы Югары Советы Рәисенең, Татарстан Республикасы Вице-президентының һәм Татарстан Республикасы Премьер-министрының ярдәмчеләре; халык депутатлары җирле Советлары рәисләренең урынбасарлары, җирле хакимият башлыкларының урынбасарлары; җирле Советлардагы һәм җирле хакимияттәге аппаратларның, комитетларның, бүлекләрнең җитәкчеләре һәм урынбасарлары, эшләр буенча идарәчеләре, ярдәмчеләр, киңәшчеләр, консультантлар;

3) баш белгечләр;

4) әйдәүче белгечләр;

5) белгечләр.

Дәүләт органының штатлар расписаниесендә эш урынының исеме әлеге орган эшчәнлегенең юнәлешен чагылдырырга тиеш.

<u>6 статья.</u> Белгечлек таләпләре

Дәүләтнең конституциячел эш урыннары буенча белгечлек таләпләре Татарстан Республикасы Конституциясе һәм Татарстан Республикасының башка закон актлары тарафыннан билгеләнә.

Дәүләтнең иң югары һәм баш хакими эш урыннарына белгечлек

таләпләре Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Югары Советы Рәисе, Татарстан Республикасы юстиция министры актлары тарафыннан билгеләнә.

Дәүләт эше урынына дәгъваланучы затларның түбәндәгеләре булу зарур:

1) баш белгеч урынына - әйдәүче белгеч урынында 3 елдан да ким булмаган эш стажы һәм юнәлешле югары белеме;

2) әйдәүче белгеч урынына - белгечлек буенча 2 елдан да ким булмаган эш стажы һәм юнәлешле югары белеме;

3) белгеч урынына - юнәлешле югары белеме яки юнәлешле урта белеме нигезендә 2 елдан да ким булмаган эш стажы.

Дәүләтнең хакими эш урыннарына башка таләпләр закон актлары һәм эш урыннары хакындагы күрсәтмәләр тарафыннан билгеләнә.

Дәүләтнең хакими эш урынына кандидат белгечлек буенча имтихан тапшырырга тиеш.

## Ш б ү л е к

## Дәүләт хезмәткәре

<u>7 статья.</u> Дәүләт хезмәткәре

Әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә түләүле дәүләт эше урынын биләүче һәм ант иткән зат дәүләт хезмәткәре була.

Дәүләт эше урынын биләүче һәм хакими вәкаләтләр йөкләнелгән дәүләт хезмәткәре дәүләт хезмәтенең урындагы заты була.

Дәүләт хезмәткәрләренә хезмәт турындагы законнарның әлеге Закон тарафыннан билгеләнгәннән гайреләре кагыла.

8 статья. Дәүләт хезмәткәренең бурычлары

Дәүләт хезмәткәренең бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) эш урыннары буенча каралган вәкаләтләрне, дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары чыгарган законнарны һәм башка норматив актларны үтәү;

2) җитәкчеләрнең үз вәкаләтләре чикләрендә чыгарылган әмерләрен, боерыкларын һәм күрсәтмәләрен үтәү, моңа законсызлары һәм кешелек абруен кимсетә торганнары керми;

3) дәүләт органында билгеләнгән хезмәт регламентын, хезмәт этикасы нормаларын үтәү һәм дәүләт хезмәтен шәхси мәнфәгатьләрдә файдалануга китерә торган гамәлләрне кылмау;

4) башка дәүләт хезмәткәрләре эшенә булышлык күрсәтү, үзе хезмәт итүче дәүләт органының абруе үсүгә ярдәм итү;

5) гражданнарның, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның мөрәҗәгатьләрен вакытында карау, аларны үз вәкаләтләре чикләрендә гадел хәл итү;

6) кирәк очракта, дәүләт органы җитәкчесенең күрсәтмәсе буенча, хезмәт турындагы законнарга таянып, үз белгечлеге чикләрендә эстәмә эш башкару;

7) хезмәт урыннарындагы вазыйфаларын башкару өчен кирәкле белгечлек дәрәҗәсен саклау;

8) эш урыны күрсәтмәсе нигезендә башка вазыйфаларны да үтәү.

9 статья. Дәүләт хезмәткәренең хокуклары

Дәүләт хезмәткәре түбәндәгеләргә хаклы:

1) дәүләтнең тиешле эш урыны буенча эш урыны вәкаләтлә-

ренең асылын һәм күләмен язма рәвештә рәсмиләштерүне һәм аларның үтәлеше өчен техник-оештыру шартларын тудыруны таләп итәргә;

2) гамәлдәге законнар нигезендә, хезмәт вазыйфаларын үтәү өчен кирәк булган мәгълүматны дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, иҗтимагый берләшмәләрдән, предприятиеләрдән, учреждениеләрдән һәм оешмалардан билгеләнгән тәртиптә соратырга һәм бушлай алырга;

3) хезмәт вазыйфаларын үтәүгә мөнәсәбәтен һәм белгечлеген исәпкә алып, эш урынында күтәрелүне яисә эш хакының күләмен арттыруны дәгъваларга;

4) кертемнәр буенча процентлар рәвешендә керемнәр һәм кыйммәтле кәгазьләрдән дивидендлар алырга;

5) үз шәхесе хакындагы барлык материаллар, бәяләмәләр һәм башка документлар белән, шәхси эшенә кертелгәнче үк, беренче мәртәбә соратуга ук танышырга, шулай ук үзе биргән аңлатмаларның шәхси эшенә теркәлүен таләп итәргә;

6) үзенең намусын һәм абруен кимсетә торган мәгълүматларны кире кагу өчен эш урынында тикшерүне таләп итәргә;

7) һөнәр берлекләренә берләшергә;

8) законда башкасы каралмаган булса, җәмәгать берләшмәләрендә торырга.

Законда һәм эш урыны күрсәтмәсендә каралган башка хокуклар да дәүләт хезмәткәрләренә кагыла.

<u>10 статья.</u> Дәүләт хезмәткәрләренең җаваплылыгы

Дәүләт хезмәткәренең үзенә йөкләнгән вазыйфаларны үтәмәве яисә тиешенчә үтәмәве, шулай ук әлеге Законда билгеләнгән чик-

ләүләрне үтәмәве дисциплинар җаваплылыкка китерә.

Дисциплинар җәзаларның төрләре, аларны куллану һәм алар турында шикаять белдерү тәртибе закон тарафыннан билгеләнә.

Дәүләт хезмәткәрләре үз гаепләре аркасында китерелгән зыян өчен законнар нигезендә матди җаваплылыкка тартылалар.

Дәүләтнең конституциячел эш урыннарын биләүче дәүләт хезмәткәрләре законда билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә чакыртып алынырга яисә эш урыныннан азат ителергә мөмкин.

Җитәкче әмеренең дөреслегенә шикләнүче дәүләт хезмәткәре бу хакта аңа кичекмәстән хәбәр итәргә тиеш. Бу очракта, әгәр җитәкче, хезмәткәренең каршы килүенә дә карамастан, үз әмерен язма рәвештә расласа, дәүләт хезмәткәре җаваплылыктан азат ителә. Вазыйфаи хата ясаган дәүләт хезмәткәре, җаваплылык турындагы мәсьәләне билгеләнгән тәртиптә хәл иткәнче, үзен эш урынына билгеләгән яки сайлап куйган орган яисә җитәкче тарафыннан хезмәт вазыйфаларын үтәүдән вакытлыча азат ителергә мөмкин.

<u>11 статья.</u> Дәүләт хезмәте белән бәйле чикләүләр

Дәүләт хезмәткәренең түбәндәгеләргә хакы юк:

1) законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, башка түләүле эш урынын биләргә;

2) шәхсән үзе яисә ышанычлы затлары аша эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, шул исәптән, милек рәвешләренә карамастан, хуҗалык итүче субъектларга идарә итүдә катнашырга, моңа Законда билгеләнгән очраклар керми;

3) законнарда башкасы каралмаган булса, хуҗалык итүче субъектларның советы әгъзасы яисә идарә әгъзасы булып торырга;

4) опекунлык һәм тәрбия итү (попечительство) вазыйфаларын түләү бәрабәренә башкарырга;

5) дәүләт органында яки җирле үзидарә органында өченче затларның эшләре буенча ышанычлысы яисә вәкиле булырга;

6) дәүләт мөлкәтен, шул исәптән матди-техник, финанс һәм мәгълүмат белән тәэмин итү чараларын хезмәткә кагылышсыз максатларда файдаланырга;

7) кызыксынучы органнардан һәм затлардан хезмәт вазыйфаларын үтәү яисә үтәмәү белән бәйле рәвештә акчалата бүләк алырга, башкача законсыз файда күрергә;

8) эш ташлауларда һәм башка гамәлләрдә катнашырга;

9) дәүләт хезмәткәренең эш урыны вәкаләтләрен дингә мөнәсәбәтне пропагандалауда файдаланырга;

10) хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибендә бастырып чыгарган язмалары һәм чыгышлары өчен гонорарлар алырга;

11) хезмәт вазыйфаларын үтәү белән бәйле булмаса, хокукый затлар һәм гражданнар исәбенә чит илгә сәфәрләргә барырга; моңа халыкара шартнамәләр нигезендә яисә Татарстан Республикасының дәүләт органнары һәм аларның административ-территория берәмлекләре белән чит дәүләтләр арасындагы үзара килешү буенча башкарылучы чит ил хезмәт сәфәрләре керми.

Дәүләт хезмәткәре әлеге статьяны бозган очракта, аңа карата дициплинар җаваплылык чаралары кулланыла, хәтта биләгән эш урыныннан азат ителергә дә мөмкин.

12 статья. Дәүләт серен саклау

Дәүләт хезмәткәре дәүләт серен, хезмәт серен һәм закон тарафыннан саклануч башка серне, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән киткәч тә, сакларга тиеш, эш урыны вазыйфаларын үтәгәндә

гражданнарның шәхси тормышына, намусына һәм абруена кагылышлы мәгълүм булган белешмәләрне сер итеп сакларга һәм, законда каралган очраклардан тыш, аларны алуны таләп итмәскә, шулай ук эштән киткәннән соң үзенең хезмәт эшчәнлеген билгеләүче предмет турындагы һәм дәүләт сере, хезмәт сере яисә закон тарафыннан саклаучы башка сер турындагы мәсьәләләр буенча мәгълүматларны предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар һәм хосусый затлар мәнфәгатьләрендә законнарда билгеләнгән чор дәвамында кулланмаска тиеш.

Дәүләт органының җитәкчесе дәүләт органының эшчәнлеген тәэмин итү мәнфәгатьләрендә гражданнарга бирелергә тиешле һәм дәүләт сере дип саналучы мәгълүматларның составын билгеләнгән тәртиптә урнаштыра һәм аларны саклауны оештырган өчен җаваплы була.

Дәүләт хезмәткәре җинаять эше кузгатылган очракта гына һәм, бу хакта дәүләт органы җитәкчесен язма рәвештә кисәтсә генә, дәүләт сере, хезмәт сере яисә закон тарафыннан саклаучы башка сер дип саналучы мәгълүматларга карата шаһитлык белешмәләре бирергә яисә белдерү ясарга хаклы. Бу очракта дәүләт сере, хезмәт сере яисә закон тарафыннан саклаучы башка сер турында мәгълүмат алган дәүләтнең урындагы затлары аның саклануы өчен җаваплы була.

Хезмәт серенә түбәндәгеләр кертелми:

дәүләт органының төзелмәсен чагылдыру, нинди эшләр белән шөгыльләнүе, адресы, дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт вәкаләтләре исемлеге, дәүләт хезмәтенең стандартлары;

гражданнарның хокукларына һәм ирекләренә, хокукый затларның хокукларына кагылышлы мәсьәләләр хакында норматив актлар;

гражданнарның һәм хокукый затларның дәүләт органнарына

һәм дәүләтнең урындагы затларына мөрәҗәгатьләрен карауның тәртибе;

гражданнарның һәм хокукый затларның мөрәҗәгатьләренә бәйле рәвештә дәүләт органнарының һәм хокукый затларның карарлары;

гражданнарның хокукларына һәм ирекләренә кагылышлы мәсьәләләр хакында хезмәт күрсәтмәләре;

гамәлдәге законнар нигезендә яшереп сакланырга тиешле булмаган мәгълүматлар.

Дәүләт хезмәтеннән киткәннән соң дәүләт хезмәткәре дәүләт органы җитәкчесенең таләбе буенча дәүләт хезмәте белән бәйле булган барлык эш кәгазьләрен, һәр төр документларны кире кайтарырга тиеш. Ул вафат булган очракта бу бурыч дәүләт хезмәткәренең варисларына һәм туганнарына йөкләнә.

Хезмәт турындагы мәгълүматларны массакүләм мәгълүмат чараларына һәм башка органнарга дәүләт органы җитәкчесе яисә аның тарафыннан вәкаләт тапшырылган дәүләт хезмәткәре бирә.

13 статья. Дәүләт хезмәткәрләре өчен гарантияләр

Дәүләт хезмәткәрләренә түбәндәгеләр гарантияләнә:

1) акчалата түләүләр һәм закон актларында каралган башка түләүләр һәм пособиеләр;

2) хезмәт вазыйфаларын үтәүне тәэмин итәрлек хезмәт шартлары;

3) ял (отпуск) итү урынына бару һәм аннан кайту хакын түләп, ел саен түләүле ял;

4) дәвалану өчен тотылган чыгымнарны каплап, дәүләт хезмәткәренә һәм аның гаилә әгъзаларына медицина хезмәте күрсәтү;

360



5) уку чорында акчалата түләүләрне калдырып, яңа һөнәргә өйрәтү һәм белгечлеген арттыру;

6) дәүләт органы бетерелгәндә яисә штатларны кыскартканда эш урынындагы хезмәт хакын (окладын) саклаган килеш һәм белгечлеге нигезендә башка дәүләт хезмәтенә күчерү яисә, соңгы эш урынындагы акчалата түләүләрне саклап һәм эшкә урнаштыруны гарантияләп, өч айдан алты айга кадәр яңадан укыту (яңа белгечлек үзләштерү); законнарда каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәткәре ризалыгыннан башка аны зарак түләнә торган эшкә күчерүне тыю;

7) пенсия белән тәэмин итү һәм гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә пособиеләр түләү;

8) хезмәт вазыйфаларын үтәү белән бәйле рәвештә вафат булу очрагын, гомеренә, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә китерелгән зыянны, шулай ук хезмәт чорында яисә хезмәттән киткәннән соң да, әмма хезмәт вазыйфаларын үтәү нәтиҗәсендә авырып китүләрне яисә хезмәткә сәләтен югалтуларны дәүләт тарафыннан тиешле бюджет хисабына иминләштерү;

9) үтәлүче хезмәт вазыйфаларының рәвешен искә алып, законда каралган тәртиптә хезмәт транспортын биреп торган яисә хезмәт хаҗәтләрендә шәхси транспортын кулланган өчен тиешле бюджет хисабыннан компенсация түләү;

10) дәүләт хезмәткәрен һәм аның гаилә әгъзаларын көч кулланудан, янаулардан, мәсхәрә итүләрдән һәм хезмәт вазыйфаларын үтәү белән бәйле рәвештә хокукка каршы кылынган башка гамәлләрдән яклау;

11) әлеге Законның 27 статьясындагы 3 пунктта, 28 статьясындагы 4,5 пунктларда күрсәтелгән сәбәпләр аркасында отставкага киткәндә, яңа эш (хезмәт) урынына урнашканчы, акчалата

түләүләр күләмендә пособие түләнә, әгәр яңа эш (хезмәт) урынында хезмәт хакы элеккегесеннән түбәнрәк булса, элеккеге акчалата түләү суммасына җитәрлек күләмдә өстәмә түләү башкарыла. Түләү яисә өстәмә түләү вакыты дәүләт хезмәткәре отставкага киткәннән соң бер елдан да артмаска тиеш;

12) дәүләт хезмәткәре вафат булган очракта аның гаиләсенә тиешле бюджет хисабыннан еллык акчалата түләүләр күләмендә бер мәртәбә пособие бирелә;

13) акчалата түләүләр, пенсия һәм дәүләт хезмәткәренә бирелүче башка түләүләр законнарда каралган тәртиптә индексацияләнергә тиеш.

<u>14 статья.</u> Дәүләт хезмәткәренә акча түләү

Дәүләт хезмәткәренә түләнә торган акчаларга хезмәт хакы һәм хезмәтнең аерым шартлары өчен, озак еллар хезмәт иткән өчен, сыйнфый дәрәҗә һәм башкалар өчен хезмәт хакына өстәп түләнә торган өстәмәләр, шулай ук компенсация түләүләре һәм пособиеләр керә. Акчалата түләүләр тиешле дәүләт бюджеты исәбеннән түләнә.

Дәүләт хезмәткәренең хезмәт хакы биләгән хезмәт урынына карап билгеләнә. Дәүләт хезмәтендәге һәр эш урыны буенча хезмәт хакының арттырылган күләме дәүләт хезмәтендәге элеккеге эш урынында түләнгән хезмәт хакы күләменнән уртача 25 процентка артык булырга тиеш.

Озак еллар хезмәт иткән өчен, сыйнфый дәрәҗә, хезмәтнең аерым шартлары һәм башкалар өчен дәүләт хезмәткәренә түләнә торган өстәмәләрнең күләмнәре һәм тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

Дәүләт хезмәтенең аерым төрләрендә дәүләт хезмәткәрләренә Татарстан Республикасы законнарында каралган тәртиптә һәм шартларда билгеләнә торган салым ташламалары бирелергә мөмкин.

15 статья. Дәүләт хезмәткәренә компенсация түләүләре һәм пособиеләр

Дәүләт хезмәткәренә хезмәт буенча командировкалар өчен, күченүләр өчен, торак өчен түләүләргә бәйле чыгымнар, транспорт өчен түләүләр, гамәлдәге законнар нигезендә билгеләнүче башка компенсация түләүләре һәм пособиеләр бирелә.

16 статья Дәүләт хезмәткәрен пенсия белән тәэмин итү

Дәүләт хезмәтендә кимендә 25 ел хезмәт иткән дәүләт хезмәткәрләре тиешле елларын эшләгән өчен пенсия алырга, вакытыннан элек пенсиягә китәргә хаклылар, әмма картлык буенча пенсиягә чыгу яшенең законда билгеләнгән вакытыннан ике елдан да алданрак булмаска тиеш. Дәүләт хезмәткәренә тиешле елларын эшләгән өчен дәүләт хезмәтен туктаткан көнгә кадәр яисә картлык буенча пенсиягә чыгу хокукы яшенә җиткән көнгә кадәр биләгән эш урынындагы хезмәт хакының 80 проценты күләмендә пенсия билгеләнә. Әлеге пенсия, шушы урында эшләүче дәүләт хезмәткәрләренең акчалары артуын исәпкә алып яисә тормышның кыйммәтләнүеннән чыгып, индексацияләү тәртибендә законнар нигезендә даими рәвештә яңадан каралырга тиеш. Тиешле елларын эшләгән өчен пенсияләр картлык буенча пенсияләрнең иң зур күләме чикләрендә Пенсия фонды акчалары исәбеннән түләнә, ә аннан артып киткән очракта арткан сумма Татарстан Республикасының республика бюд-

жеты исәбеннән түләнә.

Дәүләт хезмәткәре вафат булган очракта аның гаилә әгъзаларын пенсия белән тәэмин итү Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнар нигезендә башкарыла.

17 статья. Дәүләт хезмәткәрләрен бүләкләү

Хезмәт вазыйфаларын үрнәк рәвештә башкарган, озак еллар һәм бик әйбәт эшләгән, хезмәтендә башка казанышларга ирешкән өчен түбәндәге бүләкләүләр кулланыла:

1) рәхмәт белдерү
2) акчалата бүләкләү;
3) кыйммәтле бүләк белән бүләкләү;
4) дәүләт бүләкләре белән бүләкләү;
5) гамәлдәге законнарда каралган башка бүләкләүләр.

Дәүләт хезмәткәрләренә акчалата бүләк квартал һәм ел йомгаклары буенча премияләр бирү рәвешендә, гаять мөһим яисә катлаулы дәүләт бурычларын үтәгән өчен, шулай ук дәүләт хезмәткәрләренең юбилейлары уңаеннан бүләкләү рәвешендә бирелә.

Әлеге Законның 27 статьясындагы беренче өлешенең 1 пунктында һәм 28 статьяның беренче өлешендәге 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән нигезләрдә отставкага киткәндә дәүләт хезмәткәренә акчалата бүләк тапшырыла, ул, отставкага китә торган көнгә кадәр билгән эш урынындагы хезмәт хакын ун тапкыр арттырып, тиешле бюджет исәбеннән бирелә.

364



## 1У бүлек

## Дәүләт хезмәтендә эшләү

<u>18 статья.</u> Дәүләт хезмәтенә алу

Гамәлдәге законнар нигезендә барлык гражданнар дәүләт хезмәтенә керергә хаклы.

Дәүләт хезмәтенә алганда, әгәр законда башкасы каралмаган булса, гражданнарның кәсби әзерлекләре үзләре урнаша торган хезмәт урыны таләпләренә туры килсә, расасына, милләтенә, теленә, җенесенә, тәрҗемәи һәм мөлкәти хәленә, яшәү урынына, дингә мөнәсәбәтенә, инануларына, кайсы иҗтимагый берләшмәләрдә һәм һөнәр берлекләрендә торуларына бәйле рәвештә турыдан-туры яисә читләтеп эшләнә торган нинди дә булса чикләүләр тыела.

Граждан түбәндәге очракларда дәүләт хезмәтенә алына алмый:

1) хөкем тарафыннан тулысынча яисә өлешчә хезмәткә яраксыз дип табылса;

2) хөкем тарафыннан мәгълүм бер вакыт дәвамында дәүләт хезмәтендә эшләү хокукыннан мәхрүм ителсә;

3) медицина учреждениесе бәяләмәсе нигезендә хезмәт вәкаләтләрен башкарырга комачаулык итә торган авыру табылса;

4) хезмәтләрендә бер-берсенә турыдан-туры буйсыну яки тикшереп тору күздә тотылганда Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән очраклардан гайре, дәүләт хезмәтендәге урындагы зат белән якын кардәш яисә башка төрле кардәш (ата-аналары һәм ир белән хатын, аларның абый-энеләре, апа-сеңелләре, ата-аналары һәм ир белән хатынның балалары) булса;

5) чит дәүләт гражданлыгына ия булса;

6) Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән башка очракларда.

Законда башкасы каралмаса, башка төр тәртипкә буйсынучы затлардан кала, дәүләтнең административ-хакими эш урынына, тиешле белеме булганда, конкурс тәртибендә белгечлек имтиханы нигезендә алына. Законда каралган очракларда эшкә алганчы тикшерү уздырылырга мөмкин. Кешенең шәхси (гаилә) тормышындагы хәлләр тикшерелми.

Дәүләт хезмәтенә сайланган яисә билгеләнгән дәүләт хезмәткәренә тиешле дәүләт органының таныклыгы бирелә.

<u>19 статья.</u> Дәүләт хезмәткәренең анты

Дәүләт хезмәтенә алынганда граждан ант итә:

"Татарстан Республикасына тугры булырга, Татарстан Республикасы Конституциясен һәм Татарстан Республикасы законнарын тайпылышсыз үтәргә, дәүләт хезмәте тарафыннан үземә йөкләнгән вазыйфаларны һәм хокукларны ялгышмыйча, намус белән, фәкать закон нигезендә генә, бар көчемне кызганмыйча, Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрен истә тотып башкарырга ант итәм".

Ант бер тапкыр бирелә. Антның имза салынган тексты дәүләт хезмәткәренең шәхси эшендә саклана. Ант дәүләт хезмәткәрен дәүләт хезмәткәрләре исемлегенә кертү өчен нигез булып тора.

Дәүләт хезмәтенең аерым төрләрендә антның эчтәлегендәге үзенчәлекләр Татарстан Республикасының закон актлары тарафыннан билгеләнә.

20 статья. Дәүләт хезмәтендәге шартлар

Дәүләт хезмәтендә эш вакыты законнарда билгеләнгән вакыттан ким була алмый.

Дәүләт хезмәткәренә 30 календарь көне дәвамында ел саен түләүле ял билгеләнә. Дәүләт хезмәтенең аерым төрләрен башкаручы дәүләт хезмәткәрләре өчен закон актлары тарафыннан ел саен түләүле озынрак ял билгеләнергә мөмкин. Тиешле елларын эшләгән дәвердә дәүләт хезмәткәренә түләүле өстәмә ял бирелә:

5 елдан алып 10 елга кадәр эшләгәннән соң - 5 календарь көне;

10 елдан алып 15 елга кадәр эшләгәннән соң - 10 календарь көне;

15 елдан күбрәк эшләгәннән соң - 15 календарь көне.

Тиешле еллар эшләүне билгеләү тәртибе һәм шартлары Татарстан Республикасында гамәлдә булган законнар тарафыннан билгеләнә.

Законнарда билгеләнгән очракларда дәүләт хезмәткәренә: аерым фатир яисә йорт рәвешендә хезмәт урыныннан торак мәйданы, файдалану өчен транспорт бирелә яисә әлеге чыгымнарны каплау өчен тиешле бюджет исәбеннән компенсация түләнә.

Эш буенча командировкага җибәрелгән дәүләт хезмәткәренә юл документлары һәм кунакханәдә урын алу, эш урыны белән тәэмин ителү, элемтә һәм транспорт чараларыннан файдалану мөмкинлеге алу буенча өстен хокуклар бирелә.

Дәүләт хезмәткәренә бер елга кадәр түләүсез ял бирелергә мөмкин.

21 статья. Дәүләт хезмәткәрләрен аттестацияләү

Дәүләтнең хакими эш урынын биләүче дәүләт хезмәткәрләре аттестация узарга тиеш.

Аттестация законнарда билгеләнгән тәртиптә 4 елга 1 мәртәбәдән дә сирәгрәк уздырылмый.

Аттестация комиссиясен дәүләт органы җитәкчесе оештыра.

Аттестация комиссиясе дәүләт хезмәткәрен үзе биләгән эш урынына лаек түгел дип тапса, ул яңа һөнәр өйрәтүгә җибәрелергә, түбәнрәк эш урынына төшерелергә яисә эштән азат ителергә мөмкин.

22 статья. Дәүләт хезмәтендә күтәрелү

Дәүләт хезмәтенә беренче мәртәбә кабул ителүче гражданнар өчен, шулай ук дәүләтнең башка хезмәтенә күчерелүче дәүләт хезмәткәрләре өчен алты айга кадәр сынау чоры билгеләнергә мөмкин. Сынау дәверендә дәүләт хезмәткәренә әлеге Законның нигезләмәләре тулысынча кагыла. Сынау гамәлдәге законнардагы таләпләр нигезендә билгеләнә. Дәүләт хезмәткәренең мәгълүм сәбәпләр аркасында эштә булмаган вакыты сынау чорына кертелми.

Әгәр сынау чоры узганнан соң дәүләт хезмәткәренең биләгән эш урынына туры килүе хакында тискәре карар кабул ителмәсә, ул сынауны үткән дип санала, аны эшкә билгеләү турында өстәмә карарлар кабул ителми, сынау чоры дәүләт хезмәте стажына кертеп исәпләнелә.

Сынау дәверендә тискәре нәтиҗә булган очракта, дәүләт органы җитәкчесе дәүләт хезмәткәрен эшеннән азат итә.

Дәүләт хезмәтендә күтәрелү хокукы дәүләт хезмәткәре үзе-

нең хезмәт вазыйфаларын уңышлы һәм намус белән башкарганда һәм буш эш урыны булганда гына, шулай ук стажировка нәтиҗәләрен исәпкә алып, буш эш урыны таләпләренә яраклы рәвештә яңа һөнәргә өйрәнү һәм белгечлеген арттыру уагач кына, аттестация комиссиясе тәкъдиме буенча, әңгәмә уздырылгач гамәлгә ашырыла.

<u>23 статья.</u> Дәүләт хезмәткәрләренең сыйнфый дәрәҗәләре

Дәүләтнең хакими эш урыннарын биләүче дәүләт хезмәткәрләренә сыйнфый дәрәҗәләр бирелә.

Һәр сыйнфый дәрәҗә, биләнелгән эш урынына, белгечлеккә һәм эш стажына карап, түбәндәгечә бирелә:

дәүләтнең иң югары хакими эш урынындагы дәүләт хезмәткәренә - 1,2 һәм 3 сыйныфлы дәүләти гамәли киңәшче;

дәүләтнең баш хакими эш урынындагы дәүләт хезмәткәрләренә - дәүләти баш киңәшче;

баш белгечләргә - 1,2 һәм 3 сыйныфлы баш киңәшче;

әйдәүче белгечләргә - дәүләт хезмәтенең 1,2 һәм 3 сыйныфлы киңәшчесе;

белгечләргә - дәүләт хезмәтенең 1,2 һәм 3 сыйныфлы референты.

Гамәлдәге законнар нигезендә дәүләт хезмәтенең кайбер төрләрендә сыйныфлы дәрәҗәләрнең исемнәре башкача да булырга мөмкин, шулай ук дәүләт хезмәткәренең сыйнфый дәрәҗәсен күрсәтә торган рәвешле кием һәм аерымлык билгеләре кертелергә мөмкин.

Сыйнфый дәрәҗәләр билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Югары Советы Рәисе һәм Дәүләт хезмәткәрләре мәнфәгатьләре буенча Татарстан Рес-

публикасы Президенты каршындагы департамент тарафыннан бирелә.

Беренчел сыйнфый дәрәҗә дәүләт эш урынына билгеләгәндә конкурс комиссиясе тәкъдиме буенча бирелә. Шуннан соңгы сыйнфый дәрәҗәләр Татарстан Республикасы Президенты актларында билгеләнгән тәртиптә тапшырыла.

Сынау чорында дәүләт хезмәткәренә сыйнфый дәрәҗә бирелми. Конкурс комиссиясе сынау чорын узу хакында карар кабул иткән очракта, сыйнфый дәрәҗә сынау чорын уңышлы үткәннән соң бирелә.

Сыйнфый дәрәҗә бирелгән дәүләт хезмәткәренә Сыйнфый дәрәҗә бирү турында грамота тантаналы төстә тапшырыла.

Сыйнфый дәрәҗәсе булган дәүләт хезмәткәре дәүләтнең конституциячел эш урынына сайланганда яисә билгеләнгәндә,шушы эш урынында булган дәвердә әлеге сыйнфый дәрәҗә саклана.

Отставкадагы дәүләт хезмәткәре үзенә бирелгән сыйнфый дәрәҗәсен саклый һәм аны "отставкадагы" дигән сүз белән куллана.

<u>24 статья.</u> Дәүләт хезмәтендә икенче эштә эшләү

Дәүләтнең хакими эш урынындагы дәүләт хезмәткәре түләүле икенче эштә эшләргә тиеш түгел.

Дәүләтнең хакими эш урынындагы хезмәт вазыйфаларын үтәү белән бергә, дәүләт органы җитәкчесе дәүләт хезмәткәренә дәүләтнең башка эш урынындагы бүтән вазыйфаларны да кушарга яисә эштә вакытлыча булмаган дәүләт хезмәткәренең вазыйфаларын да тапшырырга мөмкин, әмма бу аның белеменә яисә кәсби әзерлегенә туры килергә тиеш. Бу очракта дәүләтнең икенче дәүләт хезмәтен башкарган өчен яисә эш урынында вакытлыча булмаган дәүләт хезмәткәренең вазыйфаларын үтәгән өчен дәүләт хезмәткәренә ул би-

ләгән эш урынындагы хезмәт хакының 50 проценты күләмендә дәүләт органы җитәкчесе тарафыннан өстәмә түләү билгеләнә.

25 статья. Дәүләт хезмәтен туктатуның гомуми нигезләре

Дәүләт хезмәтен туктатуның гомуми нигезләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) дәүләт хезмәткәренең отставкага китүе (27,28 статьялары);

2) дәүләтнең хакими эш урынын биләүче дәүләт хезмәткәрен эштән азат итү (29 статья);

3) дәүләт хезмәткәрләре өчен билгеләнгән чикләүләрне үтәмәү сәбәпле эштән азат итү (11 статья);

4) дәүләт хезмәте булмаган башка эшкә күчү;

5) дәүләт хезмәткәренең ризалыгы белән аны башка дәүләт органына эшкә күчерү.

26 статья. Татарстан Республикасы Президентын вазыйфаларыннан азат итү

Татарстан Республикасы Президенты үз вазыйфаларыннан Татарстан Республикасы Конституциясендә каралган тәртиптә азат ителә.

27 статья. Дәүләтнең конституциячел эш урынын биләүче дәүләт хезмәткәренең отставкасы

Дәүләтнең конституциячел эш урынын биләүче дәүләт хезмәткәренең отставкасы түбәндәге рәвештә башкарыла:

1) эш урынындагы вәкаләтләр чоры узу нәтиҗәсендә отставкага чыгу;

2) эш урынына тиешле рәвештә сайлап яисә билгеләп куйган органның яки җитәкченең карары буенча мәҗбүри отставкага җибәрү;

3) эш урынына тиешле рәвештә сайлап яисә билгеләп куйган органның яки җитәкченең карарына принципиаль ризасызлык белдереп отставкага китү;

4) гаилә хәлләренә яки сәламәтлегенә бәйле рәвештә шәхси үтенече буенча отставкага китү.

28 статья. Дәүләтнең хакими эш урынын биләгән дәүләт хезмәткәренең отставкасы

Дәүләтнең хакими эш урынын биләүче һәм сыйнфый дәрәҗәсе булган дәүләт хезмәткәренең отставкага җибәрелү рәвешләре түбәндәгечә:

1) дәүләт хезмәткәрләренең билгеле бер яшькә җитеп отставкага китүе;

2) пенсия яшенә җиткәч үзе теләп отставкага китүе;

3) дәүләт хезмәткәренең үзе теләп отставкага китүе;

4) югарыдагы органның яисә җитәкченең карарларына һәм гамәлләренә дәлилләнгән ризасызлык белдереп отставкага китү;

5) дәүләт хезмәткәре биләгән дәүләт эш урынының бетере-

лүе. Дәүләт органының ябылуы турындагы акт бер үк вакытта шушы органдагы барлык эш урыннарының бетерелүе хакындагы акт булып тора.

Әлеге статьяның беренче өлешендәге 1 пункт нигезендә отставкага китү: ирләр өчен - 65 яшькә, хатын-кызлар өчен 60 яшькә җиткәч гамәлгә ашырыла. Билгеле бер яшькә җиткәч отставкага киткәндә дәүләт хезмәткәренә салымнар салынмый торган акчалата бүләк бирелә.

Дәүләт хезмәткәре әлеге статьяның беренче өлешендәге 3 пункт нигезендә отставкага китү турында үтенеч биргәннән соң, әгәр яклар килешүендә башкасы каралмаган булса, өч ай буена хезмәтен башкаруны дәвам итәргә тиеш.

Әлеге статьяның беренче өлешендәге 4 пункт нигезендә отставкага китү турындагы үтенеч Дәүләт хезмәткәрләре мәнфәгатьләре буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы департаментта карала.

<u>29 статья.</u> Дәүләтнең хакими эш урынын биләүче дәүләт хезмәткәрен эштән азат итү

Хакими урын биләгән дәүләт хезмәткәрен эштән азат итү тиешле орган җитәкчесенең карары белән түбәндәге очракларда рөхсәт ителә:

1) антын бозганда;

2) дәүләт хезмәтенә алынгандагы сынауның нәтиҗәләре канәгатьләнерлек булмаганда;

3) дәүләт хезмәткәренә карата элегрәк дисциплинар җәза чаралары кулланылмаган булса, аның үзенә йөкләнгән вазыйфаларын мәгълүм сәбәпләрсез үтәмәгәндә яисә тиешенчә үтәмәгәндә;

4) билгән эш урынына аттестация нәтиҗәләре буенча туры килмәвен таныганда;

5) гаепләүче хөкем карарының закон көченә керүе сәбәпле;

6) даими яшәү өчен Татарстан Республикасыннан читкә китү сәбәпле;

7) дәүләт хезмәткәрен хәрби хезмәткә чакырганда яисә ул уку йортына кергәндә (укуның көндезге төре);

8) дәүләт хезмәткәре дәүләт органы белән бергә башка җиргә хезмәткә күчкәндә, шулай ук хезмәт шартларының асылдан үзгәрүе аркасында әлеге дәүләт органында эшләүдән баш тартканда.

## У бүлек

## Дәүләт хезмәтенә идарә итү

<u>30 статья.</u> Дәүләт хезмәтенә идарә итү

Дәүләт хезмәтенә идарә итү дәүләт хезмәтен кадрлар белән тәэмин итүгә, оештыру һәм норматив-хокукый яктан тәэмин итүгә, дәүләт хезмәткәрләренең хокукларын гамәлгә ашыруны һәм вазыйфаларын үтәүне, дәүләт хезмәткәрләренә билгеләнгән чикләүләрнең һәм гаранитияләрнең үтәлешен тикшереп торуга юнәлгән.

Дәүләт хезмәтенә идарә итү түбәндәгеләр тарафыннан гамәлгә ашырыла:

Дәүләт хезмәткәрләре мәнфәгатьләре буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы департамент;

дәүләт органының кадрлар бүлекчәләре.

Дәүләт хезмәткәрләре мәнфәгатьләре буенча Татарстан Рес-

публикасы Президенты каршындагы департаментның төп бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

дәүләт хезмәтен кадрлар белән тәэмин итүне фаразлау һәм планлаштыру эшен оештыру һәм аңа җитәкчелек итү;

дәүләт хезмәткәрләренең исемлекләрен алып бару;

дәүләт хезмәткәрләренең һөнәр өйрәнүләрен, белгечлекләрен күтәрүне һәм стажировка узуларын оештыру һәм шуларга ысулый җитәкчелек итү;

дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәте өлкәсендәге фәнни тикшеренүләрне хокукый-норматив яктан тәэмин итү эшләрен җайга салу;

дәүләт хезмәте стандартларын әзерләүне оештыру һәм үтәлешен тикшереп тору;

аттестация комиссияләренең составын раслау;

конкурс һәм белгечлек комиссияләрен оештыру һәм составын раслау;

аттестация, белгечлек имтиханнары һәм конкурслар нәтиҗәләре буенча дәүләт хезмәткәрләренең шикаятьләрен карау;

хезмәт бәхәсләрен хәл итү;

гражданнарның дәүләт хезмәткәрләренә карата шикаятьләрен һәм мөрәҗәгатьләрен карау. Дәүләт хезмәткәрләре буенча департамент үзенең эшчәнлеген Татарстан Республикасы Президенты раслаган Нигезләмә буенча гамәлгә ашыра.

<u>31 статья.</u> Дәүләт хезмәте стандартлары

Дәүләт хезмәте стандартлары дәүләт хезмәтен нәтиҗәле идарә итүне, дәүләт органнарының һәм дәүләт хезмәткәрләренең эшчәнлеген камил оештыруны тәэмин итәргә тиеш.

Дәүләт хезмәте стандартлары хисап тотуны һәм эш кәгазьләрен алып бару, классификацияләү, тикшереп тору, мәгълүматлар белән тәэмин итү, дәүләт органнары һәм дәүләт хезмәткәрләре эшчәнлегендәге башка рәвешләрнең һәм гамәлләрнең тәртибен билгели.

Вәкиллекле, башкарма һәм хөкем хакимияте органнарыннан кала барлык дәүләт органнары кимендә биш елга бер мәртәбә тәэелмәләренә, эшчәнлекләрен оештыруларга һәм бюджет чыгымнарының максатларына туры килү-килмәүне билгеләү өчен сертификация узарга тиеш.

Дәүләт хезмәте стандартлары һәм дәүләт органнарын сертификацияләү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

32 статья. Дәүләт хезмәткәрләренең исемлеге һәм шәхси эшләре

Дәүләт хезмәткәрләренең исемлеге аларның дәүләт хезмәтендә эшләүләре хакындагы тәртипкә китереп язылган мәгълүматлардан гыйбарәт. Исемлекне дәүләт хезмәткәрләренең шәхси эшләре һәм исәпкә алу карточкалары нигезендә дәүләт органының кадрлар хезмәте алып бара.

Дәүләт хезмәткәрләренең исемлекләре Татарстан Республикасының гомумреспублика исемлеген оештыруның нигезе булып тора, аны Дәүләт хезмәткәрләре мәнфәгатьләре буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы департамент алып бара һәм анда дәүләтнең иң югары һәм баш конституциячел, хакими эш урыннарын биләүче барлык дәүләт хезмәткәрләре хакында мәгълүматлар була.

Дәүләт хезмәткәренең шәхси эшенә Дәүләт хезмәткәрләренең

мәнфәгатьләре буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы департамент билгеләгән исемлек нигезендә мәгълүматлар туплана, уртак кагыйдәләр буенча алып барыла һәм катгый хисап тоту документы булып тора. Дәүләт хезмәткәре эшен алыштырганда аның шәхси эше яңа хезмәт урынына тапшырыла. Бер үк дәүләт хезмәткәренә берничә шәхси эш алып бару рәхсәт ителми.

Исемлеккә һәм шәхси эшкә дәүләт хезмәткәренең сәяси һәм дини карашлары, шәхси тормышы турында мәгълүматлар туплау тыела.

33 статья. Дәүләт хезмәтен финанслау

Дәүләт хезмәтен тоту өчен чыгымнар идарә итүгә тотылучы бюджет чыгымнарының бер өлешен тәшкил итә һәм аңа түбәндәге чыгымнар керә: дәүләт хезмәткәрләренә түләүләр, матди-көнкүреш һәм җәмгыяви тәэминат, дәүләт иминләштерүе, дәүләт хезмәткәрләренең белгечлекләрен күтәрү һәм яңа һөнәргә өйрәтү, дәүләт хезмәтенең идарәсен оештыру.

Дәүләт хезмәтен тоту өчен чыгымнар тиешле дәрәҗәдәге бюджет кысаларында билгеләнгән тәртиптә төзелгән смета нигезендә планлаштырыла, гамәлгә ашырыла һәм тикшереп торыла.

Бюджет ассигнованиеләрен кыскартулар дәүләт хезмәткәрләренә акча түләүне туктатуга яисә аның күләмен киметүгә нигез була алмый.

Дәүләт хезмәткәрләрен пенсия белән тәэмин итүне финанслау Татарстан Республикасының гамәлдәге законнарында билгеләнгән тәртиптә тормышка ашырыла.

Дәүләт органнары эшчәнлеген финанслау чараларын һәм дәүләт органнарында финанс чыгымнарын нәтиҗәле куллануны тикшереп тору Татарстан Республикасы законнары тарафыннан билгеләнә.

377



34 статья. Дәүләт хезмәтендә бәхәсләрне хәл итү

Татарстан Республикасы Конституциясе һәм әлеге Закон нигезендә дәүләт хезмәткәрләре Дәүләт хезмәткәрләре мәнфәгатьләре буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы департаментка яисә судка шикаять белдерергә, сайлап кую яисә билгеләү тәртибендә дәүләт хезмәтенә кабул ителү һәм аны үтәү, дәүләт хезмәтеннән азат итү яки дәүләтнең башка хезмәтенә күчү белән, дәүләт хезмәткәрләренең дисциплинар җаваплылыгы белән, дәүләт хезмәткәренең хокукый һәм җәмгыяви якланышы гарантияләрен үтәмәү белән бәйле бәхәсләр турында Дәүләт хезмәткәрләре мәнфәгатьләре буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы департаментка яисә судка мөрәҗәгать итәргә хаклы.

35 статья. Дәүләт хезмәтендә тикшереп тору һәм күзәтү

Дәүләт хезмәткәрләре дәүләт һәм халык алдында үзләренә йөкләнгән вазыйфаларны тиешенчә үтәргә тиеш.

Дәүләт хезмәткәрләренең эшчәнлеге законнар нигезендә тикшереп торыла.

Дәүләт хезмәтендәге законнарның үтәлешен күзәтүне Татарстан Республикасы Прокуроры һәм аңа буйсынган прокурорлар гамәлгә ашыра.

Татарстан Республикасы Югары Советындагы, Татарстан Республикасы Министрлар кабинетындагы һәм Татарстан Республикасы Президенты Аппаратындагы дәүләт хезмәте тарафыннан законнарның үтәлеше күзәтелми.

Татарстан Республикасы
Президенты

М.Ш.Шәймиев